وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

№23 (140). 8 июнь 2012 / 18-рәҗәп-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ





Халкыбызның үзе кебек чал тарихлы бәйрәм

▷2◁



Җыеннар традициясе өзелмәсен!

▷2,4◁



Динилек һәм миллилек – ике канатыбыз

▷3◁

## Болгарга сәфәр кылганда...

***Болгар - илебез мөселманнары өчен ислам мәгърифәтчелегенең башлангыч нокталарыннан санала. Бабаларыбыз тарафыннан 922 елда Исламның кабул ителүе татарларның гына түгел, башка халыкларның да тормышына мөселман мәдәнияте үтеп керү өчен зур этәргеч бирә. Шул сәбәптән мөселманнар, безгә шундый бүләк ясаган борынгы бабаларыбыз истәлегенә ихтирам күрсәтеп, Болгарга баралар.***

Еш кына мондый сәфәрләрне хаҗ дип атыйлар, әмма бу чынбарлыкка туры килми. Моннан тыш, Болгарга бару безнең менталитетыбызга һәм хәзерге мөселманнарга горурлык өчен нигез булган Ислам тарихы һәм мәдәниятенә якынаю булып тора. Бу шартларны без Болгарга сәфәребезне планлаштырганда истә тотарга тиешбез, моннан тыш, безнең тәртибебез һәм ислам цивилизациясе һәйкәлләренә мөнәсәбәтебез аның статусына туры килергә тиеш.

Иң киң таралган ялгышуларның берсе булып, борынгы Болгар әйләнәсендәге предметларны нинди дә булса көчкә ия дип санау тора. Моңа охшаш юк-барга ышанып, кешеләр яңа гадәтләр уйлап чыгаралар, реаль булмаган мифлар барлыкка китерәләр. Болгарга килүчеләр төркем-төркем булып борынгы чордан калган ташлар тирәли әйләнә башлыйлар, пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв) сәхабәләре каберендәге һәйкәлне үбәргә тотыналар. Бу гамәлләр ялгышу гына булып тормый, алар кешене гөнаһка да алып керәләр. Безнең гозеребезне тыңлый һәм аны үти ала торган предмет юк, бары тик Аллаһы Тәгалә генә безнең язмышыбызга йогынты ясый ала. Кем дә булса Безне Тудыручыга гына хас булган бөек көч ташта яки башка предметта дип саный икән, бу кеше иң зур гөнаһларның берсен - ширек (нәрсәне дә булса Аллаһка тиңдәш тоту) кыла. "Чыннан да, Аллаһка тиңдәш тотучыны Аллаһ ярлыкамас, моннан башка гөнаһлы булганнарны, Үзе теләсә, ярлыкар. Хактыр ки, Аллаһка тиңдәш тотучы иң зур гөнаһка батып, яла ягучы кеше булыр" ("ән-Ниса (Хатыннар) сүрәсе, 48 аять)". Күпләр, моннан тыш, болгар хәрабәләрен теләк теләү яки савыгу максатыннан сыпыралар, мәҗүси гадәтләрне кабатлаган кебек потларны үзенә карату йоласын үтәп, акчалар да аталар. Ә бит акчаны мондый файдасыз гамәлгә сарыф иткәнче, аны, чыннан да, күркәм эшләр эшләргә - сәдака бирергә, һәм шул рәвешле Аллаһның рәхмәтенә ирешергә мөмкин бит, югыйсә.

Исегездә тотыгыз: без бары тик Аллаһка гына гыйбадәт кылабыз! "Әйт син: "Аллаһ - берәү генә! Аллаһу - Самәд. Ул тудырылмаган да, тудырмаган да. Аллаһка тиңдәш юк" ("Ихлас" сүрәсе). Шуңа күрә йөрәгебез-җаныбыз өчен файдасыз һәм зарарлы гамәлләр кылганчы, Болгарга килү белән үк, үз вакытыгызны аның тарихын өйрәнүгә, борынгы корылмалар белән танышуга багышлагыз, мәчетләргә керегез, Коръән аятьләре, догалар укыгыз, тәүбә итегез. Шунысын да искәртәсебез килә: шәһәр территориясендә безнең сөекле пәйгамбәребезнең (сгв) сәхабәсе күмелгән урын бар, шуңа күрә вафат булганнар рухына дога кылыгыз, мөселман кардәшләребезгә сәлам бирегез.

Гамәлләребез үз кыйммәтен тапса иде!

***ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт һәм мәгълүмат бүлеге***

## Мөфти Илдус хәзрәт Фәизнең Болгар җыены уңаеннан МӨРӘҖӘГАТЕ

***Аллаһ Сүбхәнәһү вә Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде! Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү!***

**(Мөхтәрәм дин кардәшләребез! Мөхтәрәм Президентыбыз Рөстәм Нургали улы, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәриф улы, Тәлгать хәзрәт!..)**

Татар халкының рухи, әхлакый кыйбласын билгеләгән Болгар җиренә килү ул - бабаларыбыз рухына дога уку, зиярәт кылу булып тора.

922 елда Идел буена Багдад хәлифәтлегенең илчелеге килә һәм шул вакытта Ислам Идел буе Болгарының рәсми дине дип игълан ителә. Галимнәр раслаганча, Багдад хәлифәтлеге илчелек җибәргәнче үк Идел буе төркиләре арасында ислам таралыш ала, мәчетләр, мәдрәсәләр булган. Ш.Мәрҗани хәзрәтләре "Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" дигән хезмәтендә дә Ислам рәсми дин буларак кабул ителгәнче үк, аның халык арасында таралуына дәлил булырлык сүзләр язып калдырган.

Ислам динен рәсми кабул итү Болгар дәүләтенә мөстәкыйльлек биргән, бөтен мөселман халыклары, илләре белән элемтәләрне киңәйтү шартларын тудырган. Болгарлар белән Багдад хәлифәтлеге һәм башка күп сандагы илләр арасында дипломатик, икътисади, сәүдә, мәдәни элемтәләр урнаша.

Ислам дине алып килгән шәригать кануннары дәүләт өчен икътисади-сәяси яктан да, шушы җирлектә яшәүче халыкның иҗтимагый тормышына да бары уңай, мөһим йогынты ясый. Ислам Болгар дәүләтенең хокукый һәм фәлсәфи нигезен, халыкның әдәп-әхлагын тәшкил итә. Халык аңында бердәм кавем-милләт булып берләшү, Аллаһ ризалыгы өчен дәүләтеңә, милләтеңә файда китереп яшәү төшенчәсе ныгый.

Шулай ук Ислам болгар бабаларыбызны дөньякүләм танылган мөселман мәдәниятенә, шул чорда күзәтелгән алгарышларга якынайта. Исламны кабул иткәч тулы бер мәгариф системасы барлыкка килә. Күптөрле белем бирүче мәдрәсәләрнең гөрләп эшләве һәм аларның эшчәнлеге Казан ханлыгы чорында да дәвам иттерелүе мәгълүм.

Әлбәттә, бөтендөнья мөселманнары өчен өч кенә урын изге санала: Кәгъбәтуллаһ, Пәйгамбәребез мәчете һәм Әл-Әкса мәчете. Ләкин кайбер халыклар һәм кешеләр өчен алардан тыш та үзенең милләте, нәселе, тарихы белән белән бәйле кадерле, истәлекле җирләр барлыгын беләбез. Әлбәттә, бөтендөнья мөселманнары өчен ул урыннарның зур әһәмияте юктыр, әмма моңа карап кына берәүнең дә башкаларны ул урыннарны зиярәт кылудан тыярга хакы юк. Шәһри Болгар - безнең ерак ата-бабаларыбызның, Аллаһ тарафыннан Адәм гәләйһиссәләмгә әманәт итеп бирелгән Ислам динен кабул итеп алган урын. Халыкның бергә җыелып үз-үзенә, якыннарына, туганнарына: "Без ислам дине буенча яшибезме? Балаларыбызга динебезне, тарихыбызны, мәдәниятебезне өйрәтәбезме? Ата-бабаларыбыз динен, телен, әхлагын саклыйбызмы?" – дигән сорауларны бирүендә, уйлануында, шулай ук, догалар укып, дин әһелләре сөйләгән вәгазьләрне меңләгән кешеләр - җәмәгать белән бергә тыңлап, күңелен рухландырып кайтуында бернинди гөнаһ юк.

Ризаэддин Фәхреддин, Шиһабетдин Мәрҗани кебек олуг галимнәребез бирегә, Болгарга еш килгәннәр. Шиһабетдин хәзрәт: "1235 елда мин әби-бабаларыбыз рухына дога кылырга дип Болгарга бардым. Аллаһ гамәлләремне кабул итсә иде. Амин. Амин. Болгарда ике зур манара бар, берсе Җәмигъ мәчете янында, ул 73 баскычлы. Аннан көнчыгыштарак икенче манара, анысында 42 баскыч, бу манарага мин үзем мендем", - дип язган.

Бүген без янә рухи күтәренкелек белән биредә яңа төзелгән күркәм мәчет ачылышында катнашабыз. Һәм биредә берничә йөз ел элек олуг дини татар галимнәре кабатлаган сүзләрне кабатлыйбыз: "Аллаһ гамәлләребезне кабул итсә иде. Амин. Амин".

Бүгенге көндә Татарстанда барлыгы 1400 гә якын мәчет. Елга йөзәр мәчет ачылган вакытларыбыз булды. Хәзер дә, Аллага шөкер, иман йортларыбыз калка тора, бүгенге көндә республикада 30 га якын мәчет төзелү стадиясендә. Халкыбызның милли бәйрәме Сабантуй алдыннан иман йортларын ачу ул – динебез үсеш алган яңа заманның үзенә күрә бер күркәм күренешенә әверелде.

Шунысы да сөендерә, тулы бер халык язмышында зур роль уйнаган тарихи Болгар җирендә, Алла боерса, мәдрәсәсе дә булачак яңа иман йорты, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан Татарстанда Коръән елы дип игълан ителгән елда ачыла. Быел татарларның Россиядә тәүге тапкыр Коръәни-Кәримне нәшер итүенә 225 ел тулды. Шушы Коръән елында яңа Болгар мәчете ачылу татар халкының дини тарихын, дөнья күләмендә мөселманнар мирасын тагын да баетучы бер күренеш итеп кабул ителә.

Рухи мирасыбызны өйрәнү, торгызу һәм үстерү халкыбыз тормышын нурландыра, динебез алгарышына, милләт булып сакланып калуга ныклык бирә, ышаныч арттыра. Шуңа күрә бердәм булып, бергәләшеп Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен милләтебезгә, илебезгә хезмәт итәргә, чын мәгънәсендә Аллаһы Тәгалә каршында оялмаслык дәрәҗәдәге кеше булып калырга насыйп итсә иде.

Аллаһ Раббыбыз догалары, сүзләре, Ислам дине белән күңелләребезне рухландырып, чистартып: "Ләәә иләһә илләллааааһү Мүхәммәдүр-расүүлүллааааһ", - дип дөньядан үтәргә, Аллаһның вәгъдә иткән җәннәтләренә керергә насыйп итсә иде. Аллаһ ил җитәкчеләре, иганәчеләр, барчабыз бербөтен булып кылган изге гамәлләребезне кабул итсә иде. Амин.

## ШӘҺРИ БОЛГАР — РУХЫБЫЗ НИГЕЗЕ

**Җучи Олысы бай шәһәр мәдәниятенә ия булган. Монгол яуларыннан соң да күпчелек элекке Харәзем, Кырым, Кара диңгез буе, Болгар шәһәрләре тернәкләнеп кенә калмыйча, моңа кадәр күрелмәгән үсеш кичерә.**

Болгар туып килүче Җучи Олысының икътисади, сәяси үзәгенә әверелә. Батый хан үзенең ставкасын шушында сайлый. Болгарда Батый үлгәнче Җучи Олысының гына түгел, бөтен Монгол империясе һәм бөек хан Мунке исеменнән 1256 елдан акча суктырыла башлый. Болгар хәрабәләрен өйрәнүгә үзенең гомерен багышлаган Мәскәү профессоры А.П. Смирнов шәһре Болгарны Көнчыгыш Европаның иң матур һәм цивилизацияле шәһәрләреннән берсе буларак тасвирлый. "Аның үзәк мәхәлләсендә җәмәгать бинаалары, шул исәптән хан сарае һәм аңа якын гына җәмигъ мәчете урнашкан... Мәчет янындагы мәйданга таш түшәлгән. Монда тагын байларның ике мавзолее бар... Үзәктәге йортлар кирпечтән салынган. Җучи Олысы чорында зур биналарга, шул исәптән җәмәгать йортларына да, җылылык идән астыннан йөргән чүлмәк торбалар челтәре аша бирелгән. Болгарлардагы инженерлык сәнгатенең үсешенә монгол яуларына кадәр үк төзелгән чүлмәк торбалардан торган суүткәргеч челтәре дәлил була ала. XIII-XIV гасырларда ул тагын да нык тармаклана һәм камилләшә. Шәһәр мәйданнарында фонтаннар бәреп торган, ясалма күлләр булган. Шулай итеп, шәһәр төзеклеге, чисталыгы, андагы җәмәгать биналарының матурлыгы белән ул чордагы Европаның күпчелек шәһәрләреннән узып киткән".



Хәтерсез, тарихсыз халыкның рухын сындыруы, аны коллыкка төшерүе җиңел. Шуңа күрә дә яулап алучылар беренче чиратта тарихи китапларны юкка чыгаралар, алып китәләр, тарихи һәйкәлләрне җимерәләр. Алар өчен җимерелгән һәйкәлләр дә, тарихны саклаган авыл, елга, чокыр исемнәре дә куркынычка әйләнә. Җимерелгән шәһәрләр, анда күмелгән әүлиялар татар халкында бик зур хөрмәткә ия булганнар. Аларга зиярәт кылу бер саваплы эш саналган. Бу - үзенә күрә тарих алдында, каһарман бабаларыбыз алдында хөрмәт белән баш ию булган. Халкыбызның үзаңын, горурлыгын һәм, гомумән, аны халык итеп саклап калуда гаять зур роль уйнаганнар. Аеруча халкыбыз өчен чын мәгънәсендә караңгы гасырлар булган XVI йөзнең икенче яртысы, XVII-XVIII йөзләрдә рухи тормышта аларның әһәмияте гаять зур. Шәһре Болгар хәрабәләре Казан ханлыгы вакытында ук дини, мәдәнимәгърифәт үзәге буларак мөселманнарның зиярәт кылу, баш ию урынына әверелә. Әйтергә кирәк, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң ул мөселманнарның бердәнбер рухи терәгенә әверелә. Казан һәм Свияжск архиепискобы Лука Канашевич (?-1758) аның хәрабәләрен җир белән тигезләргә боера. Әмма монда Пётр I нең килүен, мондагы тарихи-архитектура һәйкәлләрен саклап калу өчен чаралар күрергә боеруын аның исенә төшерәләр. Әмма Лука Канашевич шәһре Болгар һәйкәлләрен рухи юкка чыгаруның тагын да мәкерле, нәтиҗәле әмәлен таба. Мөселманнарның бу изге җирдән гайрәтен кайтару өчен иң изге булган шәһре Болгар үзәгенә бик биек чиркәү салдыра һәм шул исемдәге Успения ирләр монастыре төзеттерә. Болгардагы хәрабәләрнең исемнәре алыштырылып, оештырылган монастырь ихтыяҗларына буйсындырылалар. Аларның исемнәрен генә түгел, тирә-юньдәге елга, күл исемнәренә дә үзгәртелә (Британ, Голлан күлләре, Иерусалим чокыры һ. б.).

Бүген шәһре Болгар зур янарыш кичерә. Халкыбыз рухи кытлык кичергән вакытта яңадан ул безнең ныклы рухи терәгебезгә әверелә бара.

**Гамирҗан ДӘҮЛӘТШИН,**
**тарих фәннәре докторы,**
**Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры**

# Халкыбызның үзе кебек чал тарихлы бәйрәм

**Һәр елны көтеп алган Сабантуйларның килеп чыгышы халкыбызның үзе кебек үк чал тарихлы, ул ерак гасырларга барып тоташа. 921 елда Идел буе Болгар дәүләтенә Багдадтан, Гарәп хәлифәтеннән илче һәм галим Ибне Фазлан килгәч, аны Яушәр елгасы буенда үткәрелгән җыенга алып барганнар.**

Борынгы болгарларның ничек күңел ачуларын, күп төрле бәйгеләрдә көч сынашуларны күреп, хәйран калган илче. Ул бу хакта үзенең сәяхәтнамәләрендә язып калдырган. Менә нинди ерак гасырларны тоташтыра безнең бу күркәм милли бәйрәмебез.

Сабантуй сүзенә килгәндә, "сабан" сүзе ике төрле мәгънәгә ия. Беренчесе - җир сөрү коралын аңлатса, икенчесе - яз көне чәчелгән ашлык (сабан ашлыгы) мәгънәсенә ия. "Туй" сүзе исә шатлык, өмет, шөкрана кылу, оптимизм булган бәйрәм мәгънәсенә ия. Безнең татар халкында борын-борыннан язгы киеренке кыр эшләрен тәмамлаганнан соң печәнгә төшкәнче җыйналып, сабаннан соң сайрашу йоласы булган. Аны үткәрү өчен матур табигатьле елга буе яки урман аланы сайланган. Бар халык бер җиргә, бер мәйданга тупланганга Сабан туен җыен, мәйдан дип тә йөрткәннәр. Анда оештырылган ярыш һәм уеннарның да хикмәте бар. Тарихка күз салсак, төзелгәннән бирле Идел буе Болгар дәүләтенә читтән өзлексез һөҗүмнәр булып торган. Рус кенәзләре дә, монголлар да, башкалар да еш кына яу белән килгәннәр. Дошманнарга каршы тору өчен безнең бабаларыбызга физик көч тупларга, көрәш алымнарын үзләштерергә дә кирәк булган. Сабантуйдагы бил алышуларда барыннан да бигрәк шул күздә тотылган. Дини Сабантуйларда сөңге ярышлары да оештырылу моның ачык мисалыдыр.

Тарихи чыганаклардан билгеле булганча, Сабан туен элек елга ике тапкыр - язын һәм көзен үткәргәннәр. Яз көне көрәш кебек саулык өчен куркыныч ярышларга алынмаганнар, алар көздәгесенә калдырылган. Чөнки ул чакларда әле спорт ярышларының аерым кагыйдәләрен, нечкәлекләрен белеп бетермәгәннәр. Имгәнә калганда җәйге эшләрне кем башкарыр дигән уй сагайткан аларны. Элек чабышкылар бармак белән генә санарлык булганга, ат узышларында алар бик аз катнашкан. Һәр эшне төптән җигелеп тарткан атларны, ахыры аяныч тәмамланганга, ярышка кертмәгәннәр. Гомумән, эш хайваннарын ярышта узыштыру гөнаһ саналган. Кызлар Сабантуй батырларына һәм чабыш атларына бирү өчен тастымал чиккәннәр.

Элекке Сабантуйлар хәрәм ризыклар булмавы белән дә үзенчәлекле. Борынгы бәйрәмнәрдә эчеп сәрхүшләнеп йөрүчеләр күзәтелмәгән. Эсселекне басу өчен катыклы су, әйрән, салкын чишмә суы сатылган, аерым һөнәр ияләре, кәсепчеләр үз товарларын тәкъдим иткән.

Шунысы тагын да куанычлы, татар халкының ерак гасырлардан килгән күркәм чарасы бүгенге көндә интернациональ бәйрәмгә әйләнде. Ул төрле ярышлар, уеннар өстәлү белән генә түгел, бар яклап та баетылды. Бер мәйданга ничәмә-ничә төрле милләт вәкиле җыелып, бергәләп күңел ача, шатлана, бәйгеләрдә дустанә шартларда бил алыша. Аннан соң бу милли бәйрәмебез булган Сабан туе Россия киңлекләрен узып, торган саен Төркия, Сан-Франциско, Финляндия, Австралия, Америка кебек ерак чит илләрне дә колачлый. Ул шулай татарларны дөньяга таныта, дуслык җепләрен суза, ныгыта. Без моңа бик шатбыз.



Әмма әле күңелне тырнап торган мәсьәләләр дә юк түгел. Күп җирләрдә асылыбызга тугрылык сакланса да, кайбер ямьсез күренешләр милли бәйрәмебезне чуарлый. Әйтик, соңгы вакытларда бәйрәм урынында төрледән-төрле исерткеч эчемлекләр, дуңгыз итеннән әзерләнгән шашлык сату безне гореф-гадәтләребезгә каршы килә, алар кешеләрнең нәфесләрен җиңә алмауларына этәрә. Соңгы вакытларда Сабан туйларда хәләл ризыкларны пропагандалау, тантана алдыннан муллалардан вәгазьләр сөйләтеп, милли асылыбызга тартылу сизелсә дә, бәйрәм мәйданында авызына бармак буе тәмәке капкан, кендек, колак, борыннарына персинглар таккан, кулына сыра шешәсе тоткан ярымшәрә, салмыш татар милләтле кыз-кыркыннарны күрү, ни кызганыч, халкыбызга һәм бәйрәмебезгә хөрмәтне киметә. Исереп дүрт аякланган, сүгенүче ир-атлар хакында сөйлисе дә юк инде. Аларны күргәч, күңелгә ничек тә бу адәм балаларына тәүфыйк иңдерәсе, әби-бабаларыбызның гореф-гадәт, йолаларына, милли рухыбызга тугрылыкны саклап каласы иде дигән уй уза.

Ничек кенә булмасын, Сабан туе һәрберебезнең көтеп алынган милли бәйрәме. Барлык кардәшләребезне бәйрәм белән котлап, аларның һәрбарчасының да дуслары, туганнары, якыннары янәшәсендә ялларны исәнлектә-саулыкта, җан тынычлыгы, кәеф күтәренкелеге белән күңелле итеп уздыруларын телибез. Бу изге бәйрәмебезгә һәрберебез дә күңел җылыбызны да өстик. Сабан туйлары мөбарәк булсын!

***Айгөл НУРИЕВА***

# ҖЫЕННАР ТРАДИЦИЯСЕ ӨЗЕЛМӘСЕН!

**"Җыен" дигән халык бәйрәменең иң тирән тамырлары һун һәм борынгы төрки бабаларыбызның яз ахырына һәм җәй башына туры килүче календарь йолаларына ук барып тоташа. Борынгы төрки телдә јӳgӳn / йыгын - "скопление", "сборище" мәгънәсендә. Кан кардәшлегенә һәм күмәк күчмә хуҗалык алып баруга корылган кабилә-ыруг башлыклары һәм әгъзалары, җәйгә чыгар алдыннан бергә җыелып, узган елның нәтиҗәләре һәм агымдагы елның бурычлары турында фикер алыша**

Төрки кабиләләр төрле регионнарга таралып, утрак тормышта игенчелек һәм хайван асрау белән шөгыльләнә башлаганнан соң да электән килгән кардәшлек мөнәсәбәтләре һәм күмәкләшеп яки үзара киңәшләшеп эшләү, яшәү традициясе юкка чыкмаган, ә яңа шартларга ярашып, дәвам иткән. Үзара кардәш кавемнәр һәм ыруглар, авыл-авыл булып, теге яки бу төбәккә төпләнгәннәр, шулай ук аерым күрше салалар белән дә туганлашып киткәннәр. Бер төркем төбәктәш һәм кардәш авыллар, бергә берләшеп, ил яки ыруг - община дип йөртелүче җәмәгать берләшмәләре хасил иткәннәр һәм шул ук вакытта җыен вилаяте ("округы") итеп тә каралганнар. Чөнки аларны уртак җыен бергә берләштергән һәм ул һәрчак үзәк авылда үтә торган булган. Җыенның исеме дә күпчелек очракта шул авылның исеме, яисә бәйрәм уза торган урын яки елга белән бәйләп аталган: "Ашыт җыены", "Тирсә җыены", "Мәллә җыены", "Биек тау җыены", "Базы җыены" һ.б. Христиан дине бәйрәмнәре белән бер үк вакытка туры килгәнлектән, кайбер якларда, мәсәлән, Татарстанның көнчыгыш һәм Башкорстанның көнбатыш районнарында яшәүче керәшеннәрдә "Микола җыены", "Тройча җыены", "Петрау җыены" дигән атамалар да барлыкка килгән. Соңгы атамалар Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, зур ыруг-җәмәгать берләшмәләренең бүлгәләнүе яки вакланувы нәтиҗәсендә туганнар. Һәм өстәп, басым ясап әйтергә кирәк: патша Россиясе халкыбызны төрлечә йотарга, этнос-милләт буларак юк итәргә тырышса да, ата-бабаларыбыз үзләренең милли бәйрәмнәреннән, барыбер, ваз кичмәгәннәр.

Административ һәм икътисади яктан килеп караганда, бертөркем авылны берләштерүче һәр ил-ыругның яки һәр җыен вилаятенең үз милке һәм үзидарәлеге булган. Чәчүлек җирләре, печән әзерли торган болыннар, көтүлекләр, урман-әрәмәлекләр уртак милек булып исәпләнгән; имана җире һәр гаиләгә җан башына, дөресрәге, ир заты санына карап бүленгән. Икенче төрле әйткәндә, җирдән, уртак милектән файдалану күмәк һәм шәхси башлангычларга нигезләнгән булган. Шул ук вакытта, күмәкләшеп бер-береңә ярдәм итү төре буларак, төрле өмәләр дә узыдырылып торган. Үзидарә һәм авылның старостасы исә халыктан салым җыю, урман кисү (лашманчылык хезмәте), юл төзү, йөк ташу эшләренә эшче көчләре бүлү, Рәсәй армиясенә рекрутлар биреп тору, мәхәлләләр белән бәйләнеш тоту, җыелыш-киңәшмәләр үткәрү кебек төрле агымдагы чаралар белән шөгыльләнгән. Бу инде, димәк, җыенның икътисади-хуҗалык һәм мәдәни оештыру вазифаларын башкаручы иҗтимагый-территориаль ил-берләшмә булуы турында да сөйли.

Ә инде алдан әзерләнеп, ыруг-общинаның үзәк авылында җыен бәйрәме уздыру берләшмә идарәлегенең аеруча җаваплы һәм абруйлы бурычы булган. Билгеле бер регионга (конфедерациягә) караучы җыеннар чиратлашып, ягъни һәркайсы үзенә билгеләнгән вакыт аралыгында уздырылган һәм май ахырыннан июнь аеның икенсе яртысна кадәр дәвам иткән. Галимнәр (Р.Уразманова, Н.Бикбулатов, Р.Кәшәфетдинов, Н.Борһанова) өйрәнеп ачыклавынча, төрле регионнарның җыен бәйрәмнәре арасында шактый зур уртаклык та, шулай ук җирле аермалар да яшәп килгән. Шул аерымлыклардан чыгып, традицион җыеннар фәндә ике төргә яки ике вариантка бүлеп карала.

Беренче төр җыеннар Казан арты татарлары, Вятка губернасының - Малмыж, Уржум, Сарапул, Алабуга һәм Уфа губернасының Минзәлә, Бөре, Бәләбәй кебек көнбатыш өлкәләрендә яшәгән типтәр татарлары өчен хас булган. Бәйрәм тантаналары ялларына аллы-гөлле тасмалар тагылган һәм кыңгыраулы дугаларына чигүле сөлгеләр бәйләнгән атларда кунакларның бәйрәм үтә торган үзәк авылга бер-бер артлы җыелуыннан башланып киткән. Аларның күпчелеге килен яки кияү ягы туганнарыннан, балалары никахлашкан кода-кодагыйлардан һәм якын дус-ишләрдән

*(Ахыры 4 нче биттә.)*



# Динилек һәм миллилек - ике канатыбыз



**Мәгълүм ки, Урта гасырларда гарәп-фарсы дөньясы гыйльми-мәдәни яктан җиһан цивилизациясенең үзәгенә, мәркәзенә әйләнә. Соңгы дәверләрдә алга киткән Гареб (Европа) тәрәккыяте үзенең үсеше белән шактый дәрәҗәдә мөселман Көнчыгышына бурычлы.**

Ислам диненең безнең борынгы әби-бабаларыбыз тарафыннан ирекле рәвештә кабул ителүе халкыбызга Шәрык кыйммәтләрен, аеруча андагы рухи казанышларны үзләштерүгә юл ача. Гарәп, бераздан фарсы, төрек-госманлы, үзбәк телләрен белү, ул телләрдәге китаплар белән оригиналда, төрле тәрҗемә-шәрехләрдә танышу Иделйортта зыялылыкның бер билгесенә әверелә. Мөселман Көнчыгышындагы Әбугалисина, имам Газәли, Фәраби, әл-Гарәби, Ф.Гаттар, Сәгъди, Җ.Руми һәм башка бик күп бөек затларның язмалары бездә киң таралыш ала, үзебезнеке кебек укыла, аларның фикер-карашлары, эшчәнлекләре рухи тормышыбызга гаять зур йогынты ясый.

Ислам дине безгә авыр елларда, аеруча колониаль изелү чорларында рухи терәк була. Безнең әби-бабаларыбыз, бик зур югалтулар бәрабәренә булса да, телебезне, гореф-гадәтләребезне, моңыбызны, милли барлыгыбызны саклап, алдагы буыннарга җиткерә алган. Бу игелекле хәрәкәтнең, эш-гамәлләренең башында шул чорның дин әһелләре торган. Моның өчен без аларга мең рәхмәтле.

Татар тарихы, күп гасырлык тереклек тәҗрибәбез шуны күрсәтә: дин һәм миллилек - яшәешебезнең ике канаты кебек. Шуларның табигый берлеге безне саклаган, инкыйраз афәтләрен исән-имин кичерергә ярдәм иткән. Кол Шәриф, Габдессәлам, Габдерәхим Утыз Имәни, Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Габдерәшит Ибраһимов, Муса Биги кебек бөек, гыйлемле затларыбыз нәкъ әнә шул хакыйкатьне тирәнтен тоеп эш иткән. Алар бүгенге көнебез өчен дә үрнәк булып торырлык. Ризаэддин хәзрәт, мәсәлән, энциклопедик табигатьле инсан: дин әһеле, тарихчы, философ, әдип, тиңсез остаз. Гарәп, фарсы, төрки телләрен белү өстенә, ул татар телендә роман-бәяннәрен, дини-гыйльми хезмәтләрен яза. Шунысы мөһим: аның татар телен белүе, язма тел-өслүбенең камиллеге хәтта Тукай тарафыннан да югары бәяләнә. Ризаэддин хәзрәтнең совет шартларында мөфтилек вазифасын башкаруы, динебез, кавемебез өчен фидакярләрчә көрәше роман-бәяннәрдә, кинофильмнарда чагылдыруны көтеп ята. Муса Ярулла Биги - мөселман гыйлеменең мәшһүр белгече - Шәрыкның күп кенә әсәрләрен, шул исәптән гарәп шагыйре әл-Мәгарринең атаклы "Әллозумият" китабын татарчага күчерә, милли әдәбиятыбызны арата, Тукайны хөрмәт итеп, аны Питер каласына да чакыра.

Совет чорындагы атеизм сәясәте, мең еллык графиканы алыштыру, меңәрләгән имамнарыбызны юк итү, сөрү аяныч нәтиҗәләргә китерде. Диннән читләштерү безнең бер канатыбызны сындырды. Шуның аркасында миллилек тә юкка чыга башлады. Телсезлек, ассимиляция киң колач алды. Әгәр дә элек халкыбыз, кайда яшәвенә карамастан, үз телен, динен сакласа, хәзер хәтта пайтәхетебез Казанда да маңкорт татарлар буа бәуарлык.

Шөкер Ходайга, соңгы елларда без үзебезнең нинди хәлдә икәнлегебезне өлешчә булса да аңлый башладык. Димәк, киләчәккә өметышаныч бар. Безгә элеккеге традицияләргә, тарихи тәҗрибәгә нигезләнеп, алга бару өчен ике канатыбызны да ныгыту шарт. Милләт язмышы, аны яшәтү, халкыбызны әхлаклы, иманлы, бәхетле итү - безнең уртак бурычыбыз. Бу изге эштә безгә бердәмлек, активлык кирәк.

Җәмгыятьнең үзе кебек, бүгенге дин әһелләре дә төрле. Аларны тәнкыйтьләүчеләр, хәзерлекләре түбән диючеләр дә табылып тора. Әмма моның объектив сәбәпләрен дә онытырга ярамый. Чөнки дин белгечләре озак еллар буе әзерләнмәде диярлек. Күңелендә иман нуры йөрткән шактый гына кешеләребез, гәрчә махсус хәзерлекләре булмаса да, динне, милләтне торгызу эшенә кереште һәм шактый гына игелекле гамәлләр дә кылды. Моның өчен без аларга рәхмәтле булырга тиеш.

Бүгенге вәзгыять дин әһелләрен ныклап, махсус хәзерләүне таләп итә. Хәзерге шартлар татар имамының татарча укый, яза белүен, вәгазьләрнең шул газиз телебездә сөйләвен таләп итә. Алардан гарәп телен, Коръәнне, дини тәгълиматны гына түгел, ә халкыбызның телен, тарихын, мәдәниятен дә белү сорала. Ә бит татарның бөек тә, гыйбрәтле дә тарихы, искиткеч бай рухи мирасы бар. Миллилекнең төп күрсәткече - телебез - искиткеч бай. Без галим-голәмә бу хәзинәләрне өйрәнү, бүгенге укучыга җиткерү юнәлешендә көчебез җиткән кадәр тырышабыз. Мин әдәбият тарихчысы, татар-Шәрык мәдәни бәйләнешларын өйрәнүче. Элекке язма мирасны тикшергәндә, минем исемакылым китә: анда никадәр дини, әхлакый, инсани байлык, хәзинә! Рабгузыйның "Кыйссасел-әнбия" әсәре, Мәхмүд Болгариның "Нәһҗел-фәрадис"ы, Тажеддин Ялчыголның "Рисаләи Газизә"се, госманлыдан кергән "Мөхәммәдия" китабы - боларда бит бүгенге көнгә авазадаш, кирәкле нәрсәләр дөнья кадәр.

Без бер йөкне - милләт йөген тартабыз. Шуңа күрә безгә - имамнарга, галим-голәмәгә, әдипләргә - ешрак очрашырга, үзара киңәшергә, бер-беребезгә ярдәм итәргә кирәк.

Татарны чукындыру, руслаштыру юнәлешендә бик нык активлык күрсәткән миссионер-профессор Ильминскийның "татарлык Ислам белән көчле" дигән гыйбрәтле сүзләре бар. Бу чыннан да шулай. Шуңа күрә, хөрмәтле имамнар, милли барлыгыбызны, аеруча газиз телебезне саклауда, үстерүдә сезгә зур һәм изге бурычлар йөкләнә. Абстракт, милләтсез мөселман юк. Гарәп, таҗик, үзбәк һәм башка кавемнәр арасында безнең татар милләте дә мөһим урын алып тора. Аның да якты Кояш астында, Җир йөзендә үз урыны, яшәргә хакы бар. Бу аңа Ходай Тәгалә тарафыннан бирелгән. Халкыбызны, милли менталитетыбызны саклау, үз-үзебезне хөрмәт итү - бу, беренче чиратта, без татарның үз эше, үз бурычы. Шуңа күрә безгә, кайда гына, кем генә булып эшләсәк тә, милләтпәрвәр, татарпәрвәр булу да зарури. Татарыбыз башка кавемнәр арасында үзенең иманы, әхлагы, инсанилыгы белән балкып, үзгәләргә куаныч биреп торырлык булсын!

***Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,***
***Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры***

# Милли хисләр



### И-И ТУГАН ТЕЛ!

**Күптән түгел кибеткә бүләккә әйбер алырга дип кергәч, очраклы гына рәвештә 15-16 яшьләрдәге өч кызның сөйләшүләренә шаһит булырга туры килде. "Ну чё, алабызмы соң бу тарелканы?" - диде берсе. "А кто её знает, нужна микән ул аңа - юкмы, хәзер у всех такой посуды навалом", - дип шиген белдерде икенчесе. Өченчесе исә: "Әйдәгез, лучше светильник подарить итәбез!" - дип тәкъдим итте.**

Шулай әйбер сайлый-сайлый, дүрттән өче русча, дүрттән бере татарча гәпләшеп торган кызларны ирексездән кызганып куйдым: "Шушымы инде бүгенге татар яшьләре? Дөньяда яшәүче тагын нинди халык үз туган телен шундый мәсхәрәле дәрәҗәгә җиткерә икән? Татарларның туган телен мондый мескен хәлгә калдыруларының сәбәбе нәрсәдә?"

Әгәр бүген: " Русча белми торган русны яки Ташкентта гомер итеп тә үзбәкчә аңламый торган үзбәкне, яисә туган теленнән кимсенүче японны, инглизне, французны күргәнегез бармы?" - дип сораlса, күпләребез: "Әлбәттә, юк", - дип җавап бирәчәк. Ә нигә соң әле без - татарлар - үз телебезне икенче сортлы тел кебек кабул итеп, русчага өстенлек бирәбез? Бер генә милләт тә үз телен онытып, башка телне үз итми. Ә без?!

Беренче карашка, бу сорау риторик рәвештә яңгырый. Татарларның үзләренә бүген татар теле кирәк түгел кебек. Хәтта милли мәктәбе булган район үзәкләрендә ата-аналар балаларын анда бирергә атлыгып тормый. Нигә? Әлеге дә баягы "ЕГЭ", "балабызның киләчәген кайгыртабыз, аның югары уку йортында укыйсы, кеше буласы бар", - дигән акланулар шушы сорауга әзер җавап булып тора кебек. Әмма... Игътибар итсәгез, җөмһүриятебездә эшләүче зур җитәкчеләр, Президенттан алып оешма җитәкчеләренә кадәр төрле дәрәҗәдәге түрәләр - нигездә, авылда татар мәктәбен тәмамлаган кешеләр. Язучылар, сәнгатьмәдәният өлкәсендәге күренекле шәхесләр, дин әһелләре һ. б., һ. б. заманында татар мәктәбендә укысалар да, Кеше була алганнар бит әле!

Ә үз туган телендә юньле-рәтле сөйләшә белмәүчене камил шәхес дип атап буламы соң? Ул нинди генә дәрәҗәле урында эшләсә дә, аралашканда ана телен вәтып-җимереп аңлашса, һичшиксез, аңа хөрмәт кими.

### "БАБА ЕГЭ"

Россиянең барлык субъектларында да мәктәп укучылары (алар нинди милләттән булуына, нинди телдә укуына карамастан) чыгарылыш имтиханнарын бары тик рус телендә генә бирү хокукына ия. Бу илдә алып барылган милли сәясәтнең асылын күрсәтә торган бер мисалдыр. ЕГЭ, ягъни Бердәм Дәүләт Имтиханы кертелү нәтиҗәсендә рус булмаган халыклар үзләренең мәгариф системасына үзгәрешләр кертергә, туган телдә укытуны киметеп, төп фәннәрне русча укыта башларга мәҗбүр булдылар. Татарстанда хәзер милли мәктәпләрнең шактые тулаем диярлек русча укытуга күчте. Ә милли мәктәп бетерелә икән, бу аерым бер халыкның киләчәге, үзенчәлеге куркыныч астына куела дигән сүз, чөнки русча укыган, рус мәдәнияте традицияләрендә тәрбияләнгән балалардан русча фикерләүче белгечләр килеп чыгачак, милләтнең талантлы уллары үз милли мәдәниятe, сәнгате өлкәсендә камил рәвештә хезмәт итә алмаячак. Дөрестән дә, барысы да русча укыса, үз милләтенең рухын, сулышын тоеп, барлык үзенчәлекләрен чагылдырып иҗат итә торган язучылар, шагыйрьләр, композиторлар, рәссамнар ничек үсеп чыгар соң? Милли мәдәният-сәнгать вәкилләре булдыра алганча иҗат итсә дә, аларның әсәрләре кемгә генә кирәк булыр икән? Белүебезчә, татар китабы инде хәзер сирәк укыла, милли матбугатка халык чагыштырмача аз языла. Такмак стилендә язылган җырларыбызга гына әле ихтыяҗ зур, ләкин алга таба шулай барса, аларны да халык онытып, русча "частушкалар" тыңлый башлаячак кебек...

Аллаһыга шөкер, бүген әле татарлар үз диненә хөрмәт белән карый (аның буенча яши дип әйтә алганчыга кадәр күпме гомер-вакыт узар икән?), гореф-гадәтләрне үтәргә тырыша, хәзрәтләрне өйләренә чакыра.Кызганычка, еш кына мәҗлескә килүчеләр мулланың вәгазен аңлап бетерми , чөнки ... әйе, дөрес, чөнки татарча начар белә. Бу бигрәк тә яшьләр катнашындагы никах мәҗлесләрендә сизелә. Мулла, бичара, моны абайлап, бик гади, җайлы-аңлаешлы, хәтта рус сүзләре кушып сөйләргә тырышса да, егет белән кызның күзләрен күп мәгънәле томанлы пәрдә каплаган була. Билгеле ки, шундый гаиләдә туып үскән балалар динне, үзебезнең гореф-гадәтне генә түгел, хәтта туган милли телне дә белмичә, "әти-әни" урынына "папа-мама" дип дәшеп үсә.

Без күпме генә зарлансак та, илебезнең мәгариф системасын каплап алган "ЕГЭ" дигән "убырлы карчыкның" шомлы шәүләсе мәктәп укучыларын да, аларның ата-аналарын да өркетеп торуын дәвам итә. Котлары очкан татарлар "убырлыдан" котылыр өчен теленнән дә, гомумән, татарлыгыннан да ваз кичәргә әзер сыман...

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# ҖЫЕННАР ТРАДИЦИЯСЕ ӨЗЕЛМӘСЕН!

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

торган. Үзләренә төшкән кунаклар өчен һәр йортта, килгән күчтәнәчләрне дә кушып, мул табын әзерләгәннәр. Өй борынча ашка йөрешкәннәр, көн саен мунча яккannар. Җыен көннәре теге яки бу йортка килен төшерү, яшь кәләшнең кияү йортына күченү йоласы белән дә тәңгәл килгәнлектән, кызны озата килүче кунаклар да күп булган. Табигый инде, шау-гөр килеп җыелулар, үзара очрашу-күрешүләр, туганлашулар җыр-музыка катнашлыгында үткән һәм бу уртак бәйрәмгә үзенчәлекле ямь һәм тантана өстәгән.

Икенче яки өченче көнне - бу күбесенчә җомга, яки, ягына карап, шимбә көннәренә туры килгән - кунакларны яланга, "кыр җыены"-на алып чыкканнар. Аның характерлы бер үзенчәлеге шунда оештырылучы бәйрәм базары белән бәйле. Һәр елны бер үк җирдә сәүдә палаткалары корганнар һәм аларга, гадәттәгечә, конфет-пряник, чикләвек, бадьян, канәфер, дарчин кебек төрле тәм-том яки галантерея товары сатучылар һәм кырык тармачылар рәте килеп ялганган. Кайбер төбәкләрдә халык җыелган шул ук мәйданда аю биетү тамашасы да күрсәткәннәр, балалар һәм яшүсмерләр таганда атынганнар. Һәр тарафта музыка яңгырап торган. Биек тау дип аталган бер кыр җыенына багышланган мәкаләсендә Карл Фукс (ул җыен 1834 елда була) бәйрәм барышында татарларның дәртләнеп гармунда, скрипка белән курайда уйнаулары һәм биюләре, янә иң кызыгы - бер җирдә дә аракы сатылмаганлыгы турында яза.

Әлеге төр җыеннар базар-сәүдә һәм мәйданда узган тамашалар белән генә чикләнмәгән. Бераз читтәрәк, агачлар арасында, яисә күтәртелгән тәртәләргә ябылган торыпша күләгәсендә аерым гаиләләр, самавырлар куеп, чәй эчеп утырганнар. Бөгелмә һәм Баулы төбәгендә ышыкта утыру өчен чатырлар да корганнар.

Яшьләр дә күңел ачуның төрле үзенчәлекле әмәлләрен тапканнар: бизәлгән атлар җигелгән арбаларда егетләр-кызлар, җыр җырлап һәм уйнап-гәпләшеп, базар тирәли әйләнеп йөргәннәр. Шулай ук җыен көннәрендә рөхсәт ителгән иректән файдаланып, яшь-җилкенчәк төрле җырлы-биюле уеннар да оештырганнар. Түгәрәк әйләнеп яки парпар тезелеп, шулай ук ике төркемгә бүленеп башкарыла торган мондый уеннар бер читтәге мәйданда, яисә, ягына карап, су яки урман буенда, шулай ук яисә тауда үткәрелгән. Менә Зыя Ярмәкинең шундый уенны тасвирлаган "Юкәле тау" шигыреннән өзек:

Булса бәйрәм, ямьле тауга яшь егет, кызлар чыга,
Кайный бәйрәм ашлары, бер яшь егет гармун сыза.

Яшь күңелләр ашкына, җырлый, уйный, сикерә, көлә,
Төрле шатлыклы уен һәм "кыз алышу"лар да була.

Ул хозурлык, ул матурлык, башка тауда юк бере,
Җәй үтеп, кыш килсә, күңелем минем шунда йөри.

Гадәт буенча, яшьләр ике-өч көн рәттән күңел ачканнар, берберең белән якыннан танышу, беренче мәхәббәт тойгыларының бөреләнүе һәм булачак никах мөнәсәбәтләренә нигез салыну да еш кына шушы иркенлек чорына туры килгән. Кайбер төбәкләрдә уеннарны карарга, үзләренчә күз-колак булырга дип урта яшьтәге кешеләр дә килә торган була.

Җыеннарның беренче төре күп якларда менә шулай үткән. Димәк, җыен тантаналары кардәш-ыру җыелу һәм аларны, шул исәптән кияү йортына күчүче киленне һәм килен ягы туганнарын каршылау, төп йортта кунакларга сый-хөрмәт күрсәтү һәм бергәләп аштан-ашка йөрешү, бәйрәм сәүдәсе яки базары оештырылу һәм җыелышып шунда чыгу, мәйдандагы күңелле һәм кызыклы манзараны тамаша кылу, аерым гаиләләрнең, якынтирәгә урнашып, кунаклар өчен чәй һәм сый мәҗлесе ясаулары, яшьләрнең, уен мәйданында һәм табигать кочагында җырлы-биюле уеннар оештырып, күңел ачулары кебек төрле гамәлләрне эченә алган һәм дүшәмбе көнне кунакларны шаугөр килеп озату белән тәмамланган.

Җыен бәйрәменең икенче төренә дә алда санап һәм өлешчә тәфсилләп киткән чаралар хас. Ләкин шул ук вакытта бу вариантның шактый җитди аермалы, үзенчәлекле ягы да бар. Ул аерма җыенда кыр мохите һәм күчмәчелек чорыннан ук сакланып килгән традицион бәйге-ярышлар үткәрелүгә кайтып кала. Алай гына да түгел, башкорт фольклоры белгече Кирәй Мәргән язганча, ыруг-кабилә эчендә үткәрелгән мондый җыеннарның рәсми өлеше дә булган, ягъни ыруг башлыклары һәм ил агалары узган ел йомгаклары һәм алда торган бурычлар турында фикер алышканнар һәм шуның нәтиҗәләрен халыкка җиткергәннәр. Аннары инде җыен мәйданында авыллардан җыелган ыругдашларның көчен-сәләтен сынауга, бил алышып, ярышларда катнашып, бөтен гавам алдында үз осталыкларын күрсәтүгә багышланган бәйгеләр башланып киткән. Ә ахырдан ат чабышлары килеп ялганган. Җиңүчеләргә бүләкләр авылда яшәүчеләрдән, өй борынча йөреп, алдан җыелган.

Беренче төр йолаларын гына түгел, ә төрле бәйгеләрне дә саклап дәвам иткән мондый җыеннар Казан губернасының Лаеш, Уфа губернасының Бәләбәй, Бөре, Оренбург губернасының Чиләбе, Троицк, Пермь губернасының Пермь һәм Көнгер өязләрендә һәм Сембер, Самара, Саратов губерналарының төрле мишәр авылларында уздырыла торган булган.

Әлеге вариант җыеннарының тагын бер үзенчәлеге еш кына өяз үзәгендә яки күрше рус авылларының берсендә уза торган сәүдә ярминкәләре белән бер үк вакытка туры килүе белән бәйле. Кунак төшкән йорт хуҗалары туганнары белән шул зур ярминкәгә барганнар, андый чакта мәйдан, әлбәттә, ярминкәдән соң, ягъни икенче көнне оештырылган. Һәр очракта да бәйрәмне узган чорга кыскача йомгак ясау, кереш сүз белән ачып җибәрү хуп күрелгән. Кардәшлек җепләре белән бәйләнмәгән авыллар белән дә аралашып яшәгәнлектән, җыен бәйрәменә ыругдаш булмаган яки чакырылмаган кешеләрнең дә күпләп килүе акрынлап гадәткә кереп киткән.

Белүебезчә, татар халкы яшәгән күпчелек регионнарда, бигрәк тә утрак тормыш һәм иген игү традициясе ныклап урнашкан төбәкләрдә, элек-электән үк инде Сабан туе дигән зур милли бәйрәмебез дә уздырылып килә. Элгәрге дәвердә аның уздырылу вакыты язгы чәчүгә кадәрге чорга - май ("сабан") аена туры килә торган булган. Җыен бәйрәме исә шуннан соң үткәрелгән. Әмма совет дәверендә, община-ыруглар системасы тәмам юкка чыгуга бәйле рәвештә, бу ике милли бәйрәм күпмедер дәрәҗәдә бергә берләшеп китте һәм, урыннары алмашынып, Сабантуй бәйрәме рәвешендә июнь аенда үткәрелә башлады.

***Марсель БАКИРОВ,***
***Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе***

# Милли хисләр

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

## КҮҢЕЛЕМ ТУЛЫП, ЕЛАДЫМ...

Без - татарлар - зур санлы халык, заманында дөнья күләмендә танылган абруйлы милләт. Башка халыклар арасында безнең үз дәрәҗәле урыныбыз бар һәм үсеп килүче буынны без шуның белән горурланырга өйрәтергә тиеш. Әгәр без бүген үз телебезне, йөзебезне югалтып, руслашып, европалашып бетсәк, дөньякүләм абруйдәрәҗәбездән дә колак кагачакбыз.

Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә: "Мин сезне (кешеләрне) төрле халыклар итеп яраттым - сез бер-берегезне өйрәнер өчен" ("Бүлмәләр" сүрәсе, 13 нче аять). Димәк, һәр халыкка үз телен, милли йөзен, үзенчәлекләрен саклау фарыз булып чыга түгелме соң?

Әле дә исемдә, берничә ел элек Ерак Көнчыгышта хезмәт итеп кайткан бер егет белән сөйләшергә туры килде. Рус мәктәбендә укыган, татарча юньләп белми торган татар егете. Туган яктан меңнәрчә километр ераклыктагы җирдә радиодан татар җырын ишеткән бу. "Шунда, күңелем тулып, еладым", - дип әйтте ул миңа хисләнеп...


Шулай шул, кая барсаң да, туган як үзенә тарта, олыгайган саен күңел төбендә йоклап яткан зәгыйфь милли хисләребез кем булуыбызны искә төшерә башлый. Ләкин гомеренең көз чорына җиткән, башына кәләпүш кигән, ә татарча белмәгән картны күз алдына китергәч, күңелемне шом баса. Ник, бүген без шуңа таба барабыз түгелме соң? Мәктәп тәмамлап олы тормышка аяк басучы балаларыбыз туган телдә ни сөйләшә, ни фикерли белмиләр. Бер хикмәт иясе әйткән ди бит: "Нинди телдә уйлыйсың - син шул милләттән". Ә сез, хөрмәтле укучылар, ничек һәм иң мөһиме - нинди телдә уйлыйсыз?

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе директоры***

ДУМ РТ ХАДЖ
Организация Хаджа и Умры
Оптимальный Хадж по доступной цене
(843)524-92-10
Казань,Тукая,3 www.dumrt.ru

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 9.06.12 | 2:30 | 4:00 | 13:02 | 18:38 | 21:26 | 22:56 |
| Якшәмбе | 10.06.12 | 2:30 | 4:00 | 13:02 | 18:39 | 21:27 | 22:57 |
| Дүшәмбе | 11.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:39 | 21:28 | 22:58 |
| Сишәмбе | 12.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:40 | 21:29 | 22:59 |
| Чәршәмбе | 13.06.12 | 2:29 | 3:59 | 13:02 | 18:40 | 21:29 | 22:59 |
| Пәнҗешәмбе | 14.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:41 | 21:30 | 23:00 |
| Җомга | 15.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:41 | 21:31 | 23:01 |
| Шимбә | 16.06.12 | 2:28 | 3:58 | 13:02 | 18:41 | 21:31 | 23:01 |


ООО «Ритуальные услуги»
Изготовление памятников и оград

ул. К.Насыри, 17, мечеть Аль-Марджани,
ул. 2-я Армавирская мечеть Нур-эль-Ислам,
ул. Мусина, 10, мечеть Булгар,
ул. Чистопольская, 1, мечеть Казан Нуры,
Оренбургский тракт, 193, мечеть Гадель,
ул. Мавлютова, 48, мечеть Ризван,
ул. Фучика, 52, мечеть Хузейфа,

Понедельник - пятница - с 9:00 до 18:00, суббота - с 9:00 до 13:00.
Тел.: 225-28-90, 293-25-61

Основное производство находится на мусульманском кладбище при мечети Аль-Марджани на Мамадышском тракте.
Понедельник - с 9:00 до 13:00, со среды по воскресенье - с 9:00 до 18:00, вторник - выходной.
Тел.: 8-927-427-16-02, 293-45-93

На мусульманском кладбище захоронения ведутся по канонам Шариата.
Тел. 297-28-90

Реклама

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №23 (140) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-537.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 7 июнь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**